МИНИСТЕРСТВО
СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА
И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ
ҺӘМ АЗЫК-Т0ЛЕК
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.07.2019 Казан шәһәре **№ 148/2 - пр**

**«2019-2024 елларга Татарстан Республикасында «Агростартап» проекты буенча крестьян (фермер) хуҗалыкларын булдыру һәм үстерү» ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу конкурсы турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Фермерларга ярдәм итү системасын булдыруга һәм авыл хуҗалыгы кооперациясен үстерүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертларны бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” 2019 елның 20 апрелендәге 476 номерлы карарын үтәү йөзеннән, **б о е р а м:**

1. Түбәндәгеләрне расларга:

«2019-2024 елларга Татарстан Республикасында «Агростартап» проекты буенча крестьян (фермер) хуҗалыкларын булдыру һәм үстерү» ведомство программасын (алга таба - Программа);

«2019-2024 елларга Татарстан Республикасында «Агростартап» проекты буенча крестьян (фермер) хуҗалыкларын булдыру һәм үстерү» ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу буенча конкурс турында нигезләмәне.

2. Эш башкару һәм контроль бүлегенә (Р.К.Баһаутдинова) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре (алга таба - Идарә) башлыкларына җиткерергә.

3. Идарәләр башлыклары Программада катнашу турында крестьян (фермер) хуҗалыкларына мәгълүмат бирергә тиеш.

4. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының финанслау бүлеге башлыгы М.Ә. Мәхмүтов билгеләнгән лимитлар чикләрендә акчаларны вакытында биреп җиткерүне тәэмин итәргә тиеш.

5. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Боерыкның үтәлешен үзем тикшереп торам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары - министр М.Г. Әхмәтов

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2019 елның 17 июлендә 148/2-пр номерлы боерыгы белән расланды

# «2019-2024 елларга Татарстан Республикасында «Агростартап» проекты буенча крестьян (фермер) хуҗалыкларын булдыру һәм үстерү» ВЕДОМСТВО ПРОГРАММАСЫ

**Казан - 2019**

**Эчтәлек**

Программаның паспорты 3

Программаның төп төшенчәләре

I бүлек. Программа белән хәл ителергә тиешле проблемаларны тасвирлау 7

II бүлек. Программаның максаты һәм бурычлары 8

III бүлек. Гамәлгә ашыру нәтиҗәләре һәм максатчан индикаторлар 9

IV бүлек. Программа чаралары исемлеге һәм механизм 11

V бүлек. Программаны гамәлгә ашыру сроклары 13

VI бүлек. Программаны гамәлгә ашыруның социаль һәм икътисадый нәтиҗәләрен тасвирлау 13

VII бүлек. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү һәм мониторинг 1 4

VIII бүлек. Кирәкле ресурсларга ихтыяҗны исәпләү 14

IX бүлек. Программаны гамәлгә ашыруга идарә итү системасы 15

«2019-2024 елларга Татарстан Республикасында «Агростартап» проекты буенча крестьян (фермер) хуҗалыкларын булдыру һәм үстерү» ведомство программасында катнашу турында сертификат 17

**«2019-2024 елларга Татарстан Республикасында «Агростартап» проекты буенча крестьян (фермер) хуҗалыкларын булдыру һәм үстерү» ведомство программасының**

**ПАСПОРТЫ**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2019-2024 елларга Татарстан Республикасында «Агростартап» проекты буенча крестьян (фермер) хуҗалыкларын булдыру һәм үстерү» ведомство программасы (алга таба - Программа) |
| Программаны эшләү турында карар кабул ителгән дата (аны раслау датасы, тиешле норматив актның исеме һәм номеры) | «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, 17.01.2018 № 17 |
| Дәүләт заказчысы – Программаның координаторы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба - Министрлык ) |
| Программаны төп эшләүчеләр | Министрлык |
| Программаның максаты һәм бурычлары | Грант бирүнең максаты - 2019 - 2024 елларга Татарстан Республикасында «Агростартап» проектларын гамәлгә ашыручы крестьян - (фермер) хуҗалыкларына (алга таба - КФХ) «Фермерларга ярдәм системасын булдыру һәм авыл кооперациясен үстерү» төбәк проектын гамәлгә ашыру кысаларында кече хуҗалыкларда авыл хуҗалыгы җитештерүе эшчәнлеген үстерү, авыл хуҗалыгы өлкәсендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына җәлеп итүне тәэмин итү, авыл җирлегендә халыкның тормыш сыйфатын яхшырту, авылда халыкны эш белән итүне арттыру өчен дәүләт ярдәме күрсәтү |
| Программа чараларына характеристика | Программаның бурычларын һәм максатларын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән чаралар комплексына түбәндәгеләр керә:<br>- КФХларны будыруга һәм үстерүгә грантлар бирү;<br>- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы карары белән расланган «2013-2021 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү, авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасында каралган чараларда катнашу |

| | |
|---|---|
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары | 2019 ел - 60 КФХ, 120 эш урыны булдыру;<br>2020 ел - 92 КФХ, 184 эш урыны булдыру;<br>2021 ел - 99 КФХ, 198 эш урыны булдыру;<br>2022 ел - 103 КФХ, 206 эш урыны булдыру;<br>2023 ел - 100 КФХ, 200 эш урыны булдыру;<br>2024 ел - 64 КФХ, 128 эш урыны булдыру |
| Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | 2019-2024 елларга «Фермерларга ярдәм итү системасын булдыру һәм авыл кооперациясен үстерү» федераль проектын финанслауның гомуми күләме 2723,8 млн. сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:<br>2019 ел - 418,8 млн. сум;<br>2020 ел - 327,1 млн. сум;<br>2021 ел - 351,0 млн. сум;<br>2022 ел - 366,4 млн. сум;<br>2023 ел - 582,8 млн. сум;<br>2024 ел - 677,7 млн. сум;<br>федераль бюджеттан финанслау, барысы - 2206,4 млн. сум, шулардан:<br>2019 ел 339,2 млн. сум;<br>2020 ел - 265,0 млн. сум;<br>2021 ел - 284,3 млн. сум;<br>2022 ел - 296,8 млн. сум;<br>2023 ел - 472,1 млн. сум;<br>2024 ел - 548,9 млн. сум;<br>Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслау - 517,5 млн. сум, шулардан:<br>2019 ел - 79,6 млн. сум;<br>2020 ел - 62,1 млн. сум;<br>2021 ел - 66,7 млн. сум;<br>2022 ел - 69,6 млн. сум;<br>2023 ел - 110,7 млн. сум;<br>2024 ел - 128,8 млн. сум |
| Программа чараларын гамәлгә ашыруның көтелә торган соңгы нәтиҗәләре һәм социаль-икътисадый нәтиҗәлелек күрсәткечләре | Дәүләт ярдәме белән үзләренең крестьян (фермер) хуҗалыкларын үстерү проектларын гамәлгә ашырган крестьян (фермер) хуҗалыклары саны - 518 берәмлек, шул исәптән: 2019 елда - 60 берәмлек; 2020 елда - 92 берәмлек; 2021 елда - 99 берәмлек; 2022 елда - 103 берәмлек; 2023 елда - 100 берәмлек; 2024 елда - 64 берәмлек;<br>6 ел эчендә булдырылган эш урыннары саны - 1036 берәмлектән ким түгел. |

## Программаның төп төшенчәләре

**Крестьян (фермер) хуҗалыгы –** агымдагы финанс елында Татарстан Республикасының авыл территориясендә теркәлгән, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - 209-ФЗ номерлы Федераль закон) билгеләнгән микропредприятие критерийларына туры килә торган, акчаларны тотып бетергәннән соң кимендә 5 ел дәвамында эшчәнлек алып барырга һәм крестьян (фермер) хуҗалыгын булдыру һәм үстерү проектында каралган эшчәнлек күрсәткечләренә ирешергә йөкләмә алган, башлыгы Россия Федерациясе гражданы булган һәм эшкуарлык эшчәнлегенең беренче этабын оештыруга элек яисә хәзер финанс ярдәме акчаларын, субсидияләр яисә грантлар, шулай ук яңа эш башлаучы фермерга ярдәм итү грантын алмаган крестьян (фермер) хуҗалыгы (алга таба - КФХ);

**авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы -** «Авыл хуҗалыгы кооперациясе турында» 1995 елның 8 декабрендәге 19Э-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән, Россия Федерациясе субъектының авыл территориясендә теркәлгән, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кече һәм урта эшкуарлык субъекты булып торучы һәм кимендә 5 шәхси ярдәмче хуҗалыкны һәм (яисә) башка 3 авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесен берләштерүче авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы (авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативыннан тыш). Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләреннән булган, шәхси ярдәмче хуҗалыклардан тыш, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы әгъзалары «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законда билгеләнгән микропредприятие критерийларына туры килергә тиеш. Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының бүленми торган фонды әлеге авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы әгъзасы булып торучы крестьян (фермер) хуҗалыгына бирелгән «Агростартап» гранты акчаларының бер өлешеннән дә төзелергә мөмкин. Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы «Агростартап» гранты акчалары тотылып беткән көннән соң 5 ел буена авыл хуҗалыгы кооперативларының ревизия берлегендә (союзында) тора һәм (яисә) торырга тиеш һәм үз эшчәнлеге нәтиҗәләре турында турында ел саен вәкаләтле органга ревизия бәяләмәсе тапшырырга тиеш;

**авыл территорияләре –** муниципаль район чикләрендә гомуми территория булып берләшкән авыл җирлекләре, шулай ук шәһәр округлары составына керүче (территориясендә Татарстан Республикасының администраив үзәкләре урнашкан шәһәр округларыннан тыш) авыл торак пунктлары һәм эшче поселоклар;

**мөрәҗәгать итүче** – конкурста сайлап алу нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе тарафыннан җиңүче дип игълан ителгәннән соң иң күбе 15 календарь көн дәвамында Федераль салым хезмәте органнарында КФХны дәүләт теркәвенә куярга сүз биргән КФХ башлыгы яисә Россия Федерациясе гражданы (алга таба – Мөрәҗәгать итүче);

**«Агростартап» гранты** - федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан крестьян (фермер) хуҗалыгына аның дәүләт ярдәменең башка юнәлешләре кысаларында түләнми торган һәм КФХны булдыру һәм үстерү проектын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарын финанслау өчен Федераль казначылыкның

Татарстан Республикасы буенча Идарәсендә ачылган КФХның шәхси счетына күчерелә торган акчалар (алга таба - Грант);

**грант алучы** – Программада катнашучы дип танылу өчен сайлап алу конкурсын узган һәм Грант алу өчен шартнамә төзегән мөрәҗәгать итүче.

Грант КФХ булдыру һәм үстерү проектын гамәлгә ашыруга бәйле һәм дәүләт ярдәменең башка юнәлешләре кысаларында кайтарылмый торган түбәндәге чыгымнарны финанслашу өчен бирелә:

1) «Агростартап» проектын гамәлгә ашыру кысаларында авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү максатында крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлекләре сатып алуга;

2) җитештерү һәм склад биналары, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, саклау һәм эшкәртү өчен билгеләнгән биналар төзү яисә реконструкцияләү өчен проект документациясе эшләүгә;

3) җитештерү һәм склад биналары, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, саклау һәм эшкәртү өчен кирәкле биналар сатып алу, төзү, ремонтлау, модернизацияләү һәм яңадан коруга;

4) җитештерү һәм склад биналарын, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, саклау һәм эшкәртү өчен кирәкле биналарны, янкорылмаларны һәм корылмаларны электр-, су-, газ-, җылылыкүткәргеч челтәрләренә тоташтыруга;

5) авыл хуҗалыгы хайваннары (дуңгызлардан тыш), шул исәптән кош-корт сатып алуга;

6) балык үрчетү материалын сатып алуга;

7) авыл хуҗалыгы техникасы сатып алуга, тагылма һәм эленмә җайланмаларны, йөк автомобиле транспортын, мобиль сәүдә өчен махсусдаштырылган автомобиль транспортын, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү өчен җайланмаларны (дуңгызчылык продукциясен җитештерү һәм эшкәртү өчен билгеләнгән җайланмалардан тыш) да кертеп;

8) күпьеллык үсентеләр утырту өчен утыртма материал сатып алуга;

9) әлеге КФХ әгъза булып торучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының бүленмәс фондына кимендә 25 процент, әмма 50 процентган да артык булмаган күләмдә акчалар кертү өчен;

10) Россия кредит оешмаларында әлеге исемлекнең 3,7 пунктларында күрсәтелгән максатларга алынган кредит буенча Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан акчалар алуга заявка бирелү вакытына файдалану чоры ике елдан кимрәк булган чорга бурычны түләү өчен.

Әлеге КФХ әгъза булып торучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының бүленмәс фондына кертү өчен Мөрәҗәгать итүче тарафыннан алынган акчалар түбәндәге мөлкәтне сатып алуга тотылырга мөмкин:

1) авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының җитештерү объектларына авыл хуҗалыгы продукциясен, кыргый җимешләрне, гөмбә һәм җиләкләрне, шулай ук бу продуктлар эшләнмәләрен әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү, суыту, сатуга әзерләү, төяп җибәрү, бушату өчен билгеләнгән җитештерү объектларына

җайланмалар һәм техника сатып алу, чыгарыла (җитештерелә, эшкәртелә) торган продукциянең сыйфатына һәм иминлегенә җитештерү контроле һәм ветеринария-санитария экспертизасы лабораторияләрен җиһазлау өчен җайланмалар сатып алу (авыл хуҗалыгы продукциясенең сыйфатына лаборатор анализ ясау өчен җайланмалар сатып алу).

2) Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Аквакультура (балыкчылык) өлкәсендәге классификаторны раслау турында» 2014 елның 18 ноябрендәге 452 номерлы боерыгы нигезендә «Балыкчылык инфраструктурасы объектлары һәм аквакультураны (балыкчылыкны) гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган башка объектлар, шулай ук махсус җайланмалар яисә технологияләр», дигән 4 бүлегендә, «04.01, 04.02, 04.06 кодлар төркеменнән тыш» билгеләнгән номенклатура буенча авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы тарафыннан җайланмалар сатып алу өчен;

3) авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы тарафыннан Гомумроссия продукция классификаторының икътисадый эшчәнлек төрләре буенча түбәндәге тиешле кодларына (алга таба - ОКПД 2) туры килә торган авыл хуҗалыгы техникасын, авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аның эшләнмәләре продуктларын ташу, ташыганда һәм сатканда аларның сакланышын тәэмин итү өчен махсуслаштырылган транспорт, фургоннар, тагылмалар сатып алуга: 22.22.19, 27.52.14, 28.13.14, 28.22.17.190, 28.22.18.210, 28.22.18.220-28.22.18.224, 28.22.18.230-28.22.18.234, 28.22.18.240-28.22.18.246, 28.22.18.249, 28.22.18.250-28.22.18.254, 28.22.18.255, 28.22.18.260, 28.22.18.269, 28.22.18.320, 28.22.18.390, 28.25.13.115, 28.29.12.110, 28.30.2, 28.30.3, 28.30.5-28.30.8, 28.30.91, 28.30.92, 28.30.93, 28.92.25, 28.92.50.000, 28.93.16, 28.93.2, 29.10.41.110-29.10.41.112, 29.10.41.120-29.10.41.122, 29.10.42.110-29.10.42.112, 29.10.42.120-29.10.42.122, 29.10.44.000, 29.10.59.240, 29.10.59.280, 29.20.23.120, 29.20.23.130.

## I. Программа белән хәл ителергә тиешле проблемаларны тасвирлау

Соңгы елларда авыл халкы санының кимүгә таба баруы күзәтелә, Федераль дәүләт статистика хезмәтенең Татарстан Республикасы территориаль органы белешмәләре буенча 2019 ел башына авыл халкының саны республика халкының 23 процентын тәшкил итә, 2014 ел белән чагыштырсак, ул чакта 23,9 процент булган.

Кече бизнесның үсешен ныгыту һәм яңа эш урыннары булдыру, авыл яшьләренең кызыксынучанлыгын һәм эш белән тәэмин ителешен арттыру максатларында, Программада КФХларны үстерү буенча чаралар комплексы тәкъдим ителә. Яңа эш башлаучы КФХлар шактый күп җитди проблемаларга юлыгалар: башлангыч капиталның җитәрлек булмавы, залог мөлкәте булмау аркасында кредитлар алып булмау. Соңгы елларда көнкүреш җайланмалары белән тәэмин ителеш мәсьәләсе дә кискен тора, бу да өстәмә акчалар таләп итә. КФХ, финас тотрыклыгына ирешә алмыйча, үз эшчәнлеген туктатырга мәҗбүр була.

Шул ук вакытта, шәхси ярдәмче хуҗалыклар секторында милкендә яисә файдаланууда ике гектарга кадәр яки аннан да күбрәк җирләре булган һәм товар

продукциясен җитештерүгә юнәлеш алган хуҗалыклар да барлыкка килде. Алар хәзер үк инде кайбер фермер хуҗалыкларын узып китәләр. Фактта исә билгесез статус белән, бозык җитештерү элемтәләре белән крестьян хуҗалыклары барлыкка килә. Шундый хуҗалыкларның барлыкка килүе эре күмәк предприятиеләр таркалганда аларның хуҗаларының алга таба гамәлдә булуга альтернатива булмау белән аңлатыла.

Соңгы еллардагы авыл хуҗалыгы оешмалары үсеше тәҗрибәсеннән күренгәнчә, хуҗалык эшчәнлегендә ирешкән казанышлар үз көчең һәм акчаларың белән генә авыл хезмәтчәннәренең социаль проблемаларын хәл итәргә һәм җитештерүне яңартырга мөмкинлек бирми.

Яңа КФХ булдыру шулай ук хуҗалык корылмаларын проектлаштыруга, аларны инженерлык челтәрләренә тоташтыруга, лизинг түләүләре буенча башлангыч кертем түләүгә шактый чыгымнар таләп итә.

Авылда кече хуҗалыкларга ярдәм итү буенча уздырыла торган дәүләт сәясәте кече авыл хуҗалыгы эшкуарлыгы субъектларына банкларның субсидияләнә торган кредитларыннан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары заемнарыннан файдалану мөмкинлеге бирде.

## II. Программаның максаты һәм бурычлары

Программаның максаты – авыл халкының муллыгын арттыру, яңа эш урыннары булдыру, шәһәр һәм авыл халкын үзебездә җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясе белән тәэмин итү.

Бу максатны гамәлгә ашыру һәм авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм куллану балансының тотрыклылыгы кысаларында дәүләт ярдәме түбәндәге юнәлешләр буенча биреләчәк:

сөт терлекчелеге;

эре мөгезле терлекләрне симертү;

ат үрчетү;

сарык үрчетү;

кәҗә үрчетү;

куян үрчетү;

балыкчылык;

авыл хуҗалыгы кошчылыгы;

умартачылык;

бөртекле һәм кузаклы культуралар, азык һәм техник культуралары җитештерү;

бәрәңге игү;

яшелчәчелек (ачык һәм ябык грунтта);

җиләк-җимеш культуралары үстерү;

гөмбәчелек.

Программаның бурычы – крестьян (фермер) хуҗалыклары булдыру һәм үстерү нигезендә авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүне арттыру.

## III. Гамәлгә ашыру нәтиҗәләре һәм максатчан индикаторлар

Программа чараларын гамәлгә ашыруның көтелә торган соңгы нәтиҗәләре һәм социаль икътисадый-нәтиҗәлелек күрсәткечләре.

Мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт ярдәме катнашы белән үзләренең КФХларын үстерү проектларын гамәлгә ашыра алалар.

1.1. Программа чараларын гамәлгә ашыру түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

1.1.1. Өстәмә рәвештә кимендә 1036 даими эш урыны булдыру, бу авыл территорияләрен тотрыклы үстерергә, шулай ук авыл җирлегендә халыкны урнаштыру системасын саклап калырга мөмкинлек бирәчәк;

1.1.2. КФХ булдыруга һәм үстерүгә, авыл җирлегендә традицион тормыш рәвешен саклап калуга ярдәм алу;

1.2. Программа чараларын гамәлгә ашыруның максатчан индикаторлары түбәндәгеләр була:

дәүләт ярдәме белән үз хуҗалыкларын үстерү проектларын гамәлгә ашырган КФХлар саны;

өстәмә булдырылган даими эш урыннары саны.

Программа чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәсе объективлык, дөреслелек, күренүчәнлек, каршылык критерийларына җавап бирә торган санлы күрсәткечләр белән билгеләнә.

**1 нче таблица**

**Программаның нәтиҗәсе**

| Максатлар | Бурычлар | Үтәүчеләр | Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторлар күләме | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | Бары-сы: |
| Авыл халкының муллыгын арттыру | 518 КФХ булдыру, 1036 - эш урыны | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | КФХлар санын арттыру, берәмлек | 60 | 92 | 99 | 103 | 100 | 64 | 518 |
| | | | Будырыла торган өстәмә даими эш урыннары саны, берәмлек | 120 | 184 | 198 | 206 | 200 | 128 | 1036 |

## IV. Программа чаралары исемлеге һәм механизм

4.1. Программаның төп чаралары түбәндәгеләр була:

Программаның комплексы ярдәмен тәэмин итү өчен Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәр Россия Федерациясен үстерүнең илкүләм максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указы белән расланган «Кече һәм урта эшкуарлык һәм шәхси эшкуарлык инициативасына ярдәм» Илкүләм проекты кысаларында гамәлгә ашырыла торган чаралар карала;

4.1.1. Банклардан озак сроклы һәм кыска сроклы кредитлар алу;

4.1.2. КФХлар җитештерә торган авыл хуҗалыгы продукциясен сатуны оештыру;

4.1.3. Программаның җитештерү һәм социаль объектларына инженерлык-техник инфраструктура төзү һәм ремонтлау, ул Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 - 2021 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу турында» 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы карары белән расланган дәүләт программасының «Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» ярдәмче программасы (алга таба - «Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» ярдәмче программасы) кысаларында гамәлгә ашырыла;

4.1.4. Программа проектларын үстерүгә ярдәм итү өчен КФХ башлыклары, торак шартларын яхшырту мохтаҗлыгы булганда, “Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү” ярдәмче программасы кысаларында гамәлгә ашырыла торган торак шартларын яхшырту программаларына кушыла алалар;

4.1.5. КФХ булдырырга теләүче гражданнарга Министрлык һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнарында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре (алга таба - Идарәләр) белгечләре тарафыннан һәм «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кооперациясен үстерү буенча компетенцияләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан консультация ярдәме күрсәтү.

Министрлык түбәндәгеләрне тәэмин итә:

гражданнарның Программада катнашуны уздыру һәм аның тәртибе турындагы мәгълүматтан законнар нигезендә ирекле файдалана алуын;

КФХның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 - 2021 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу турында» 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы карары белән расланган дәүләт программасы чараларында катнашуын.

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы Татарстан Республикасы заявкасы һәм Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы һәм Министрлык арасында төзелгән Килешүләр нигезендә «Кече һәм урта эшкуарлык һәм шәхси эшкуарлык инициативасына ярдәм» Илкүләм проект шартлары буенча Программа чараларын финанслаша. Финанслашу Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Фермерларга ярдәм итү системасын булдыруга һәм авыл хуҗалыгы кооперациясен

үстерүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертларны бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” 2019 елның 20 апрелендәге 476 номерлы карары белән расланган Программага ярдәм итү өчен республика бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрендә билгеләнгән шартлар нигезендә һәм лимитлар чикләрендә башкарыла.

4.2. Бюджет акчаларын тоту Программа чыгымының һәр исеме (статьясы) буенча гамәлгә ашырыла: Грант акчаларының 90 процентыннан күбрәк булмага һәм Грант алучының җәлеп ителгән акчаларының 10 процентыннан ким булмаган күләмдә.

Грант исәбенә алынган[1] барлык активлар Грант алучы исеменә теркәлергә тиеш һәм КФХ тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә һәм бары тик КФХ – Грант алучы эшчәнлегендә генә кулланылырга тиеш.

КФХны булдыруга һәм үстерүгә алынган Грант максатчан файдаланылмаган очракта, масатчан файдаланылмаган Грант суммасы законнар нигезендә тиешле бюджетларга кире кайтарылырга тиеш.

Грант алучының Грант акчалары исәбенә алынган мөлкәте Грант акчалары тотылып беткәннән соң 5 ел дәвамында Россия Федерациясе законнары нигезендә сатылмый, бүләк ителми, арендага тапшырылмый, башка затларга файдалануга бирелми, алмаштырылмый яисә пай, кертем рәвешендә взноска кертелми, башка төрле читләштерелми. Әлеге шарт Программаның Грантлар бирү буенча чараларында катнашучылар өчен катгый санала һәм бу Министрлык белән Грант алучы арасында төзелә торган шартнамәләрдә чагылдырылырга тиеш.

«Агростартап» Гранты КФХ башлыгына бары тик бер мәртәбә генә бирелә. КФХ башлыгы урта һәм кече эшкуарлыкка ярдәм итүгә юнәлдерелгән дәүләт программаларының программачыл чаралар исемлегенә кертелергә мөмкин.

4.3. Министрлык Грант алучыларның акчаларны тотуларын һәм аларның максатчан тотылыш тикшереп торуны тәэмин итә.

Бирелгән Грантлар, Грантның максатчан тотылмавы һәм (яисә) аларны алу өчен дөрес булмаган белешмәләр бирелү фактлары ачыкланганда, Министрлык исеменнән тиешле таләп алынган датадан алтмыш көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты һәм федераль бюджет keременә кире кайтарылырга тиеш.

Акчаларны масатчан файдалану өчен җаваплылык Грант алучыга йөкләнә.

4.4. Грант алучы КФХ булдыру һәм үстерү буенча Грант акчаларының максатчан тотылышы турында Министрлыкка елга ике мәртәбә (яртыеллык, еллык) хисап тапшыра, ул әлеге боерык белән расланган «2019-2024 елларга Татарстан Республикасында «Агростартап» проекты буенча крестьян (фермер) хуҗалыкларын булдыру һәм үстерү» ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер)

---

[1] Активлар Татарстан Республикасыннан читтә дә алынырга мөмкин, әмма аның территориясенә кайтарылырга тиеш.

Транспорт чаралары Грант алучылар тарафыннан Татарстан Республикасыннан читтә чикләнмичә файдаланылырга мөмкин, әмма Татарстан Республикасы территориясендә теркәлергә тиеш.

хуҗалыкларын сайлап алу буенча конкурс турында” нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) 1 нче кушымтадагы “Җыелма реестр” формасы буенча тапшырыла, тагын Нигезләмәгә 2 нче кушымта формасы буенча “Эшчәнлек турында белешмәләр” тапшырыла. Грант акчасы объектлар төзүгә (реконструкцияләүгә) тотылганда, КФХ төзелеш тәмамлану факты буенча КС-2 һәм КС-3 формасы буенча хисап тапшыра.

Тапшырыла торган хисапларның дөреслеге өчен җаваплылык КФХ башлыгына йөкләнә. Хисаплар Министрлыкка Грант акчалары алынган көннән 7 ел дәвамында тапшырыла.

Тапшырыла торган хисапларның дөреслеген Министрлык тикшереп тора.

## V. Программаны гамәлгә ашыру сроклары

Программа 2019 - 2024 еллар чорына «Фермерларга ярдәм системасын булдыру һәм авыл кооперациясен үстерү» Федераль паспорты нигезендә 2019 - 2024 елларда гамәлгә ашырыла.

## VI. Программаны гамәлгә ашыруның социаль, икътисадый нәтиҗәләрен тасвирлау

6.1. Максатка ирешүдә Программа өлешен гомуми бәяләү:

Программа чараларын гамәлгә ашыру авыл хуҗалыгы өлкәсендә түбәндәге стратегик максатларга ирешүгә ярдәм итәчәк:

авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм сату күләмнәрен арттыруга һәм аның конкуренциягә сәләтлелеген күтәрүгә, авыл халкының эш белән тәэмин ителешен арттыруга һәм тормыш дәрәҗәсен күтәрүгә, авыл территорияләрен тотрыклы үстерүгә;

авыл халкының эшлекле активлыгын үстерүгә, эшкуарлык эшчәнлеге белән кызыксынуны арттыруга.

Программа чараларын гамәлгә ашыру авылда кече хуҗалыкларны тотрыклы үстерүгә һәм аларга дәүләт ярдәме механизмнарын оптимальләштерүгә алшартлар тудыра.

6.2. Программа чараларын гамәлгә ашыруның социаль һәм икътисадый нәтиҗәләре:

Нәтиҗәдә дәүләт федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан эшсезлек буенча пособиегә түләүләр күләмен киметүдән өстәмә икътисадый табыш алачак һәм салым җыемнары артачак.

Программа чараларын гамәлгә ашыру тискәре экологик нәтиҗәләргә китерми, киресенчә, авыл хуҗалыгы җирләренең сыйфатын яхшырту буенча мәдәни-техник чаралар башкару юлы белән табигать ресурсларын саклап калуга ярдәм итәчәк.

Программаның фактта ирешелгән нәтиҗәләренең башта планлаштырылган нәтиҗәләр аермасына йогынты ясарга мөмкин булган тышкы шартларга һәм хәтәрлекләргә түбәндәгеләр керә:

финанслауның түбән булуы, бу КФХларның техник базасын һәм терлекчелек продукциясен беренчел эшкәртү цехларын модернизацияләүгә, шулай ук авыл хуҗалыгы җирләре мәйданнарын арттырырга мөмкинлек бирмәячәк;

ягулык-майлау материалларына, авыл хуҗалыгы техникасына һәм җайланмаларына, минераль ашламаларга һәм пестицидларга, терлекчелек фермаларын төзү материалларына бәяләрнең инфляция аркасында күтелгәннән артык үсүе;

аномаль һава шартлары һәм административ реформага, шулай ук федераль башкарма хакимият органнары структурасындагы үзгәрешләргә, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы арасында тиешле вәкаләтләрнең яңадан бүенешенә бәйле барлыкка килергә мөмкин булган форс-мажор хәлләр.

Күрсәтелгән хәтәрлекләр форс-мажор булалар яисә дәүләт хакимияте эшчәнлегенә бәйле булулар. Шуңа бәйле рәвештә бу хәтәрлекләрне алдан фаразлап булмый.

## VII. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү һәм мониторинг

Программа чараларын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләүне, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы арасында төзелә торган килешүдә билгеләнгән нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешү дәрәҗәсеннән чыгып, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы башкара.

2019-2024 елларда әлеге Программа кысаларында республикада төзелгән КФХлар санын 518 хуҗалыкта арттыру планлаштырыла, алар сайлап алу нигезендә дәүләт ярдәме катнашында үзләренең КФХларын үстерү проектларын гамәлгә ашыра алалар.

Министрлык түбәндәгеләрне тапшыра:

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгына Татарстан Республикасы Президенты һәм Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы арасында КФХга ярдәм буенча килешүдә беркетелгән күрсәткечне үтәү турында мәгълүматны Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнгән хисап формасы нигезендә.

## VIII. Кирәкле ресурсларга ихтыяҗны исәпләү

Программаны финанслау ел саен агымдагы елга һәм план чорына кабул ителә торган федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законнар нигезендә башкарыла.

Программада каралган барлык чараларны финанслау Программаны үтәүнең бөтен срогы дәвамында алар буенча ирешелгән нәтиҗәләрне бәяләүнең зарурлыгын

һәм чараларны гамәлгә ашыруның узган елдагы нәтиҗәлелеген исәпкә алып башкарыла.

КФХны үстерүгә «Агростартап» Грантының 2019-2024 елларга гомуми суммасы 1338,0 млн. сум тәшкил итәчәк, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан - 254,0 млн. сум.

**“Татарстан Республикасында 2019-2024 елларга «Агростартап» проекты буенча крестьян (фермер) хуҗалыкларын булдыру һәм үстерү” Программасы чараларын финанслау күләмнәре**

| Финанслау чыганаклары | 2019 ел, млн. сум | 2020 ел, млн. сум | 2021 ел, млн. сум | 2022 ел, млн. сум | 2023 ел, млн. сум | 2024 ел, млн. сум | 2019-2024 еллар, млн. сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Финанслауның гомуми күләме, барысы, шул исәптән: | 205,0 | 159,0 | 171,0 | 179,0 | 288,0 | 336,0 | 1338,0 |
| федераль бюджет | 166,0 | 129,0 | 139,0 | 145,0 | 233,0 | 272,0 | 1084,0 |
| Татарстан Республикасы бюджеты | 39,0 | 30,0 | 32,0 | 34,0 | 55,0 | 64,0 | 254,0 |
| Җәлеп ителгән акчалар | 22,7 | 17,6 | 19,0 | 19,8 | 32,0 | 37,3 | 148,4 |

Җирле үзидарә органнары карары буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары акчаларын да җәлеп итәргә мөмкин.

Бюджеттан тыш чыганаклар:

1) коммерциячел банклар акчалары - кече һәм урта эшкуарлык субъектларын кредитлау өчен банклар игълан иткән кредит ресурслары;

2) бюджеттан тыш чыганаклардан финанслана торган оешмалар арасыннан катнашучыларның акчалары (акчалар чыганагы буларак фаразлана).

## IX. Программана гамәлгә ашыруга идарә итү системасы

Программа чараларын гамәлгә ашыруга оештыру-методик идарә итүне дәүләт заказчысы һәм Министрлык йөзендә координатор гамәлгә ашыра.

Министрлык Программа чараларын әзерләү һәм гамәлгә ашыру буенча килештерелгән эшләрне тәэмин итә.

Программа чараларын гамәлгә ашыруның барышы мониторингын һәм Программаны гамәлгә ашыруда катнашучы учреждениеләрнең һәм оешмаларның эшчәнлеген һәм аларның Программаны гамәлгә ашыру буенча килештерелгән эшләрен җайга салуны Министрлык башкара.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2019 елның 17 июлендә 148/2-пр номерлы боерыгы белән расланган Программага кушымта

**«2019-2024 елларга Татарстан Республикасында «Агростартап» проекты буенча крестьян (фермер) хуҗалыкларын булдыру һәм үстерү» ведомство программасында катнашу турында**
**СЕРТИФИКАТ**

Татарстан Республикасы
Авыл хуҗалыгы һәм
азык-төлек
министрлыгының
2019 елның 17 июлендә 148/2-пр номерлы
боерыгы белән расланды

## Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы

## Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы

## СЕРТИФИКАТ

*Әлеге сертификат белән*

,

---

*(фамилиясе, исеме, атасының исеме)*

*крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күрсәтүче,*

______________________________________________________________

*( ОГРНИП һәм дата)*

*Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 20___ елның _______________ _________ номерлы боерыгы белән расланган «2019-2024 елларга Татарстан Республикасында «Агростартап» проекты буенча крестьян (фермер) хуҗалыкларын булдыру һәм үстерү» ведомство программасы буенча сайлап алу конкурсында җиңүче дип таныла һәм аңа ____________ муниципаль районында ________________________________ юнәлеше буенча крестьян (фермер) хуҗалыгын үстерүгә __________ (________________________________) сум күләмендә*

*(сүз белән язылa)*

*грант бирелә.*

*Бирү датасы* “ “ _____________ 20____ *ел.*

*Татарстан Республикасы*
*Премьер-министры урынбасары –*
*Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы*
*һәм азык-төлек министры* *М.Г. Әхмәтов*

***Серия*** ___________________________________

# «2019-2024 елларга Татарстан Республикасында «Агростартап» проекты буенча крестьян (фермер) хуҗалыкларын булдыру һәм үстерү» ведомство программасында катнашучыларны сайлап алу конкурсын уздыру турында НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Фермерларга ярдәм итү системасын булдыруга һәм авыл хуҗалыгы кооперациясен үстерүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертларны бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” 2019 елның 20 апрелендәге 476 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында” 2018 елның 17 гыйнварындагы 17 номерлы карары нигезендә әзерләнде.

1.2. Әлеге Нигезләмә дәүләт ярдәме бирү тәртибен, проектларны сайлап алу критерийларын, проектларны конкурс буенча сайлап алуны оештыру һәм уздыру максатларын, шартларын, процедурасын билгели.

Әлеге Нигезләмәдә кулланылучы төп төшенчәләр:

**крестьян (фермер) хуҗалыгы -** агымдагы финанс елында Татарстан Республикасының авыл территориясендә теркәлгән, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - 209-ФЗ номерлы Федераль закон) билгеләнгән микропредприятие критерийларына туры килә торган, акчаларны тотып бетергәннән соң кимендә 5 ел дәвамында эшчәнлек алып барырга һәм крестьян (фермер) хуҗалыгын булдыру һәм үстерү проектында каралган эшчәнлек күрсәткечләренә ирешергә йөкләмә алган, башлыгы Россия Федерациясе гражданы булган һәм эшкуарлык эшчәнлегенең беренче этабын оештыруга элек яисә хәзер финанс ярдәме акчаларын, субсидияләр яисә грантлар, шулай ук яңа эш башлаучы фермерга ярдәм итү грантын алмаган крестьян (фермер) хуҗалыгы (алга таба - КФХ);

**авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы** - «Авыл хуҗалыгы кооперациясе турында» Федераль закон нигезендә төзелгән, Россия Федерациясе субъектының авыл территориясендә теркәлгән, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль закон нигезендә кече һәм урта эшкуарлык субъекты булып торучы һәм кимендә 5 шәхси ярдәмче хуҗалыкны һәм (яисә) башка 3 авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесен берләштерүче авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы (авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативыннан тыш). Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләреннән булган, шәхси ярдәмче хуҗалыклардан тыш, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы әгъзалары «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законда билгеләнгән микропредприятие критерийларына туры килергә тиеш. Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының бүленми торган фонды әлеге авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы әгъзасы булып торучы крестьян (фермер) хуҗалыгына

бирелгән «Агростартап» гранты акчаларының бер өлешеннән дә төзелергә мөмкин. Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы «Агростартап» гранты акчалары тотылып беткән көннән соң 5 ел буена авыл хуҗалыгы кооперативларының ревизия берлегендә (союзында) тора һәм (яисә) торырга тиеш һәм үз эшчәнлеге нәтиҗәләре турында турында ел саен вәкаләтле органга ревизия бәяләмәсе тапшырырга тиеш;

**авыл территорияләре** - муниципаль район чикләрендә гомуми территория булып берләшкән авыл җирлекләре, шулай ук шәһәр округлары составына керүче (территориясендә Татарстан Республикасының администраив үзәкләре урнашкан шәһәр округларыннан тыш) авыл торак пунктлары һәм эшче поселоклар;

**мөрәҗәгать итүче** – конкурста сайлап алу нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе тарафыннан җиңүче дип игълан ителгәннән соң иң күбе 15 календарь көн дәвамында Федераль салым хезмәте органнарында КФХны дәүләт теркәвенә куярга сүз биргән, үзен «2019-2024 елларга Татарстан Республикасында «Агростартап» проекты буенча крестьян (фермер) хуҗалыкларын булдыру һәм үстерү» ведомство программасында (алга таба - Программа) катнашучы дип тану өчен конкурс комиссиясенә гариза биргән һәм әлеге Нигезләмә таләпләренә туры килә торган КФХ башлыгы яисә Россия Федерациясе гражданы (алга таба – Мөрәҗәгать итүче);

**«Агростартап» гранты** - федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан крестьян (фермер) хуҗалыгына аның дәүләт ярдәменең башка юнәлешләре кысаларында түләнми торган һәм КФХны булдыру һәм үстерү проектын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарын финанслау өчен Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча Идарәсендә ачылган КФХның шәхси счетына күчерелә торган акчалар (алга таба - Грант).

Грант КФХ булдыру һәм үстерү проектын гамәлгә ашыруга бәйле һәм дәүләт ярдәменең башка юнәлешләре кысаларында кайтарылмый торган түбәндәге чыгымнарны финанслашу өчен бирелә:

а) «Агростартап» проектын гамәлгә ашыру кысаларында авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү максатында крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлекләре сатып алуга;

б) җитештерү һәм склад биналары, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, саклау һәм эшкәртү өчен билгеләнгән биналар төзү яисә реконструкцияләү өчен проект документациясе эшләүгә;

в) җитештерү һәм склад биналары, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, саклау һәм эшкәртү өчен кирәкле биналар сатып алу, төзү, ремонтлау, модернизацияләү һәм яңадан коруга;

г) җитештерү һәм склад биналарын, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, саклау һәм эшкәртү өчен кирәкле биналарны, янкорылмаларны һәм корылмаларны электр-, су-, газ-, җылылыкүткәргеч челтәрләренә тоташтыруга;

д) авыл хуҗалыгы хайваннары (дуңгызлардан тыш), шул исәптән кош-корт сатып алуга;

е) балык үрчетү материалын сатып алуга;

ж) авыл хуҗалыгы техникасы сатып алуга, тагылма һәм эленмә җайланмаларны, йөк автомобиле транспортын, мобиль сәүдә өчен махсусдаштырылган автомобиль транспортын, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү өчен җайланмаларны (дуңгызчылык продукциясен җитештерү һәм эшкәртү өчен билгеләнгән җайланмалардан тыш) да кертеп;

з) күпьеллык үсентеләр утырту өчен утыртма материал сатып алуга;

и) әлеге КФХ әгъза булып торучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының бүленмәс фондына кимендә 25 процент, әмма 50 проценттан да артык булмаган күләмдә акчалар кертү өчен;

к) Россия кредит оешмаларында әлеге исемлекнең “в” һәм “ж” пунктларында күрсәтелгән максатларга алынган кредит буенча Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан акчалар алуга заявка бирелү вакытына файдалану чоры ике елдан кимрәк булган чорга бурычны түләү өчен.

Мөрәҗәгать итүче әгъза булып торучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының бүленмәс фондын булдыру максатлары өчен акчаларның бер өлешен куллану каралган Грантны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Мөрәҗәгать итүче тарафыннан алынган акчалар әлеге авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы тарафыннан түбәндәгеләр өчен тотылырга мөмкин:

а) авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының җитештерү объектларына авыл хуҗалыгы продукциясен, кыргый җимешләрне, гөмбә һәм җиләкләрне, шулай ук бу продуктлар эшләнмәләрен әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү, суыту, сатуга әзерләү, төяп җибәрү, бушату өчен билгеләнгән җитештерү объектларына җайланмалар һәм техника сатып алу, чыгарыла (җитештерелә, эшкәртелә) торган продукциянең сыйфатына һәм иминлегенә җитештерү контроле һәм ветеринария-санитария экспертизасы лабораторияләрен җиһазлау өчен җайланмалар сатып алуга (авыл хуҗалыгы продукциясенең сыйфатына лаборатор анализ ясау өчен җайланмалар сатып алуга).

б) Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Аквакультура (балыкчылык) өлкәсендәге классификаторны раслау турында» 2014 елның 18 ноябрендәге 452 номерлы боерыгы нигезендә «Балыкчылык инфраструктурасы объектлары һәм аквакультураны (балыкчылыкны) гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган башка объектлар, шулай ук махсус җайланмалар яисә технологияләр», дигән 4 бүлегендә, «04.01, 04.02, 04.06 кодлар төркеменнән тыш» билгеләнгән номенклатура буенча авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы тарафыннан җайланмалар сатып алу өчен;

в) авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы тарафыннан Гомумроссия продукция классификаторының икътисадый эшчәнлек төрләре буенча түбәндәге тиешле кодларына (алга таба - ОКПД 2) туры килә торган авыл хуҗалыгы техникасын, авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аның эшләнмәләре продуктларын ташу, ташыганда һәм сатканда аларның саклнышын тәэмин итү өчен махсуслаштырылган транспорт, фургоннар, тагылмалар сатып алуга: 22.22.19,

27.52.14, 28.13.14, 28.22.17.190, 28.22.18.210, 28.22.18.220-28.22.18.224, 28.22.18.230-28.22.18.234, 28.22.18.240-28.22.18.246, 28.22.18.249, 28.22.18.250-28.22.18.254, 28.22.18.255, 28.22.18.260, 28.22.18.269, 28.22.18.320, 28.22.18.390, 28.25.13.115, 28.29.12.110, 28.30.2, 28.30.3, 28.30.5-28.30.8, 28.30.91, 28.30.92, 28.30.93, 28.92.25, 28.92.50.000, 28.93.16, 28.93.2, 29.10.41.110-29.10.41.112, 29.10.41.120-29.10.41.122, 29.10.42.110-29.10.42.112, 29.10.42.120-29.10.42.122, 29.10.44.000, 29.10.59.240, 29.10.59.280, 29.20.23.120, 29.20.23.130;

**Конкурс комиссиясе** - КФХ булдыруга һәм үстерүгә грантлар бирү өчен мөрәҗәгать итүчеләр проектларын сайлап алу максатларында төзелгән ведомствоара конкурс комиссиясе;

**эксперт советы** - заявкаларны һәм Министрлык боерыгы белән расланган конкурс комиссиясе каравына документларны тапшыручы совет;

**бизнес-план** – бер эшчәнлек (тармак) юнәлеше буенча КФХ булдыру һәм үстерү планы;

**чыгымнар планы** - Мөрәҗәгать итүче тарафыннан конкурс комиссиясе раславына Грантны куллану юнәлешләре буенча статьялап бүленеп кертелгән чыгымнар сметасы;

**мөрәҗәгать итүче** - конкурста сайлап алу нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе тарафыннан җиңүче дип игълан ителгәннән соң иң күбе 15 календарь көн дәвамында Федераль салым хезмәте органнарында КФХны дәүләт теркәвенә куярга сүз биргән КФХ башлыгы яисә Россия Федерациясе гражданы (алга таба – Мөрәҗәгать итүче);

**грант алучы** – Программада катнашучы дип танылу өчен сайлап алу конкурсын узган һәм Грант алу өчен шартнамә төзегән мөрәҗәгать итүче (алга таба - Грант алучы).

Грант конкурс комиссиясе тарафыннан заявкасы расланган Мөрәҗәгать итүчегә бирелә.

1.3. Конкурс комиссиясе эшен оештыруны Министрлык гамәлгә ашыра.

1.4. Грант чыгымнар планында күрсәтелгән сатып алына торган мөлкәт, башкарыла торган эшләр өчен аларның хакыннан кимендә 10 процентын үз акчаларыннан түләргә йөкләмә алган Мөрәҗәгать итүчегә бирелә.

1.5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан Грант акчаларына алынган мөлкәт Грант акчалары тотылып беткәннән соң 5 ел дәвамында Россия Федерациясе законнары нигезендә сатылмый, бүләк ителми, арендага тапшырылмый, башка затларга файдалануга бирелми, алмаштырылмый яисә пай, кертем рәвешендә взноска кертелми, башка төрле читләштерелми.

## 2. Грантлар күләме һәм аларны бирү шартлары

2.1. Грант Грант алучыга техник-икътисадый дәлилләү нигезендә максатчан чыгымнарны финанслашу нигезендә кире кайтарылмау шарты белән бирелә.

2.2. Грант күләме, мөрәҗәгать итүченең үз акчаларын һәм аның чыгымнар планын исәпкә алып, конкурс комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

Грантның иң югары чик күләме 3 млн. сумнан артык була алмый, әмма чыгымнар планында күрсәтелгән чыгымнарның 90 процентыннан да артык түгел, күрсәтелгән КФХ әгъза булып торучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының бүленмәс фондын булдыру максатларына Грант 4 млн. сумнан артык була алмый, әмма, өстәлгән бәяләрне исәпкә алмыйча, чыгымнар планында күрсәтелгән чыгымнарның 90 процентыннан да артык түгел.

2.3. Грантлар проектланучы куәт түбәндәге шартларга туры килгәндә бирелә:

сөтчелек фермалары кимендә 24 баш сыер белән (елга кимендә 110 тоннага кадәр сөт җитештерү);

эре мөгезле терлекләр симертү фермалары кимендә 50 баш сыер белән (елга тере үлчәмдә кимендә 12 тонна ит җитештерү);

сарыклар үрчетү буенча фермалар кимендә 300 баш сарык белән, шул исәпән кимендә 100 баш ана сарык (елга тере үлчәмдә кимендә 8 тонна ит җитештерү);

савым кәҗәләре - кимендә 80 баш (елга кимендә 60 тонна сөт җитештерү );

ит юнәлешендәге кошчылык фермалары - тере үлчәмдә еллык ит җитештерү әйләнеше һәм баш саны: күркәләр - 8 мең баштан ( 60 тоннадан) ким булмаска тиеш, бройлерлар - 10 мең баштан (10 тоннадан) ким булмаска, казлар - 3 мең баштан (10 тоннадан ким булмаска) яисә үрдәкләр 6 мең баштан (12 тоннадан) ким булмаска;

йомырка юнәлешендәге кошчылык фермалары - еллык йомырка җитештерү әйләнеше һәм баш саны: йомырка сала торган тавыклар 10 мең баштан (йомырка 2,6 млн. данәдән) ким булмаска тиеш, бытбылдык - 20 мең баштан (йомырка 5 млн. данәдән) ким булмаска, казлар - 2 мең баштан (йомырка 150 мең данәдән) ким булмаска яисә үрдәкләр 2 мең баштан (йомырка 240 мең данәдән) ким булмаска тиеш;

яшь кош-корт үрчетү буенча кошчылык фермалары - тере үлчәмдә еллык артым әйләнеше һәм баш саны: күркәләр 10 мең баштан (ите 10 тоннадан) ким булмаска тиеш, бройлерлар – 10 мең баштан (3 тоннадан) ким булмаска, йомырка сала торган тавыклар - 12 мең баштан (10 тоннадан) ким булмаска, казлар - 5 мең баштан (1,2 тоннадан) еим булмаска яисә үрдәкләр 10 мең баштан (3,0 тоннадан) ким булмаска тиеш;

ат фермалары баш саны 80нән ким булмаска, шул исәптән бияләр саны 32дән ким булмаска тиеш (терел үлчәмдә ит җитештерү елга 5 тоннадан ким булмаска тиеш);

товар балыгын җитештерү (үрчетү) буенча фермалар - елга 5 тоннадан ким булмаска тиеш;

бәрәңге үстерү - кимендә 20 гектар (алга таба - га) чәчүлек мәйданы;

ачык грунтта яшелчәчелек - кимендә 10 га чәчүлек мәйданы;

ябык грунтта яшелчәчелек - кимендә 2000 квадрат метр (алга таб - $м^2$) чәчүлек мәйданы;

бөртекле һәм кузаклы культуралар җитештерү - кимендә 200 га чәчүлек мәйданы;

азык культуралары - кимендә 200 га чәчүлек мәйданы;

техник культуралар - кимендә 150 га чәчүлек мәйданы;

жиләк-җимеш культураларын үстерү - кимендә 2,6 га утыртылар торган мәйдан;

куян үрчетү - кимендә 12 мең шул исәптән кимендә 2000 ана куян (ит җитештерү - елга кимендә 20 тонна һәм тире җитештерү - елга кимендә 8 мең тире);

гөмбәчелек - кимендә 2000 м чәчүлек мәйданы;

умартачылык - кимендә 120 умарта оясы (бал җитештерү - елга кимендә 3 тонна товар балы).

2.4. Грантлар тиешле елга һәм план чорына федераль бюджеты һәм Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законнар белән шул максатлар өчен Министрлыкка каралган бюджет акчалары чикләрендә бирелә.

2.5. Мөрәҗәгать итүче Конкурста катнашу өчен түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

а) Мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Конституциясенең 65 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районының авыл территориясендә, республика әһәмиятендәге шәһәрләрдән тыш, теркәлгән яисә теркәлә торган булса, Татарстан Республикасының авыл территориясендә җитештерү эшчәнлеген алып бара яисә алып барачак, үзе башлык булып тора торган (булачак) КФХ эшчәнлеген алып бара торган урында даими яши яисә шул муниципаль берәмлеккә күченеп килергә йөкләмә алган һәм бу хуҗалык грант акчалары үзләштерелгән көннән 5 ел буена аның бердәнбер эш урыны булса;

б) Мөрәҗәгать итүче эшкуарлык эшчәнлегенең беренче этабын оештыруга финанс ярдәме акчалары, субсидияләр яисә грантлар, шулай ук яңа эш башлаучы фермерга ярдәм буенча грант алмаган яисә элек тә алмаган булса;

в) Мөрәҗәгать итүченең урта белеме яисә югары авыл хуҗалыгы белеме булса, яисә авыл хуҗалыгы белгечлеге буенча өстәмә һөнәри белем алган булса, яки авыл хуҗалыгында кимендә өч ел хезмәт стажы булса, яки кимендә өч ел шәхси яисә уртак ярдәмче хуҗалык алып бара торган булса;

г) Мөрәҗәгать итүче авырган, Россия Федерациясе Хәрби Көчләренә хезмәт итүгә алынган яисә хуҗалыкта булу яки КФХ эшчәнлегендә шәхсән катнашу мөмкинлегеннән мәхрүм итәрлек көтелмәгән хәлләр килеп чыккан очракта, ул, Министрлык белән килештереп, хуҗалык белән җитәкчелек итүне һәм Грант алуга бәйле йөкләмәләрне үтәүне үзенең туганына яки КФХ әгъзасына, Грант акчасына алынган мөлкәтне сату хокукын бирмичә, тапшырырга йөкләмә ала;

д) Мөрәҗәгать итүченең Грант акчалары тотылып беткәннән соң кимендә 5 ел дәвамында 2.3 пункттагы эшчәнлекнең берәр юнәлеше буенча КФХ булдыру яисә үстерү һәм сатыла торган авыл хуҗалыгы продукциясе күләмен арттыру буенча планы (алга таба - Бизнес-план) була;

е) Мөрәҗәгать итүченең сатып алына торган мөлкәтнең, башкарыла торган эшләрнең, күрсәтелә торган хезмәтләрнең исемнәре, аларның саны, бәяләре, финанслау чыганаклары (Грант акчалары, үз акчалары) күрсәтелгән чыгымнар планы була;

ж) Мөрәҗәгать итүче үзенә Грант бирелгәннән соң бер ел эчендә, әгәр Грант сумммасы 2 млн. яисә аннан күбрәк булса, - кимендә 2 яңа даими эш урыны

булдырырга һәм 2 млн. сумнан кимрәк булса, кимендә 1 даими эш урыны булдырырга йөкләмә ала;

з) Мөрәҗәгать итүче яңа булдырылган даими эш урыннарын Грант акчалары тотылып беткәннән соң кимендә 5 ел дәвамында сакларга йөкләмә ала;

и) Мөрәҗәгать итүче Грант акчалары тотылып беткәннән соң кимендә 5 ел дәвамында эшчәнлеген гамәлгә ашырырга йөкләмә ала;

к) Мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясе законнары нигезендә үзенең шәхси белешмәләрен тапшырырга һәм эшкәртергә ризалык бирә;

л) Мөрәҗәгать итүче Грант бирегән ел алдыннан булган авыл хуҗалыгы продукциясе күләмен 10 процентка арттыруны тәэмин итәргә йөкләмә ала;

м) КФХ «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нормалары нигезендә микропредприятие критерийларына туры килә;

н) Мөрәҗәгать итүче конкурс комиссиясенә заявка бирелгән вакытка соңгы өч ел эчендә шәхси эшкуар буларак эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырмый (яисә) үзе башлык булып тора торган КФХдан тыш, коммерциячел оешманы гамәлгә куючы (анда катнашучы) түгел. Мөрәҗәгать итүче, соңгы өч елда аның эшкуарлык эшчәнлеге чоры гомумән алганда алты айдан артыграк булмаса, конкурста катнашуга заявка бирә ала;

о) Мөрәҗәгать итүче чыгымнар планында күрсәтелгән мөлкәтнең, башкарыла торган эшләрнең, күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакыннан кимендә 10 процентын үз акчалары исәбеннән түли;

п) Мөрәҗәгать итүче акчалар хуҗалык башлыгы исәбенә кергән датадан 18 ай эчендә Гранты кулланырга һәм Грант исәбенә алынган мөлкәттән бары тик хуҗалык эшчәнлеген үстерү өчен генә файдаланырга йөкләмә ала;

р) Мөрәҗәгать итүченең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча үтәлмәгән йөкләмәләре юк, шулай ук башка хокукый актлар белән бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кайтару буенча вакыты узган бурычы юк һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында вакыты узган башка төрле бурычы юк;

с) Мөрәҗәгать итүче - юридик зат (шәхси эшкуар) үзгәртеп кору, бетерү, банкротлык процессында түгел (КФХ өчен);

т) Мөрәҗәгать итүче чит ил юридик заты түгел, шулай ук устав (җыелма) капиталында ташламалы салым салу режимын бирә торган һәм (яисә) финанс операцияләре уздырганда мәгълүматны (офшор зоналарны) фаш итүне һәм бирүне күздә тотмаучы дәүләтләрнең һәм территорияләрнең Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлегенә кертелгән дәүләт (территория) теркәлү урыны булган чит ил юридик затларының катнашу өлеше 50 процанттан артып китә торган Россия юридик заты түгел.

2.6. Грант КФХ башлыгына бары тик бер генә тапкыр бирелә.

2.7. КФХ башлыгы түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

акчалар алынган көннән 7 ел буена Министрлыкка 2 нче Кушымта нигезендә еллык һәм яртыеллык "Эшчәнлек турында белешмәләр" хисапларын тапшырырга;

Грант акчалары һәм үз акчалары тотылганнан соң, чыгымнар планы нигезендә, 1 нче Кушымтада күрсәтелгән «Җыелма реестр»ны, акчаларның максатчан тоылышын раслый торган хисап-финанс документларын (сату-алу шартнамәләрен, түләү йөкләмәләрен, накладнойларны, счет-фактураларны, башкарылган эшләрнең һәм күрсәтелгән хезмәтләрнең фотоларын, актларын), Грантны максатчан файдалану турында килештерү кәгазен тапшырырга.

**3. «2019-2024 елларга Татарстан Республикасында «Агростартап» проекты буенча крестьян (фермер) хуҗалыкларын булдыру һәм үстерү» ведомство программасында катнашу өчен конкурс комиссиясенә тапшырыла торган документлар исемлеге**

3.1. Программада катнашу өчен Мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкка түбәндәге документлар тапшырыла:

3.1.1. Форма буенча заявка, 3,4 нче кушымталар нигезендә;

3.1.2. Форма буенча анкета, 5 нче, 6 нчы кушымталар нигезендә;

3.1.3. Сатыла торган терлекчелек һәм үсемлекчелек продукциясе күләмен арттыруга юнәлдерелгән югары технологияле җайланмалар һәм авыл хуҗалыгы техникасын кулланып, фермер хуҗалыгын булдыру һәм үстерү буенча бизнес-план, аның белән бергә сату каналлары, иң күбе биш ел эчендә аклана торган торак булмаган объектларны төзүне, реконструкцияләүне яисә модернизацияләүне нигезләү, тапшырыла, шулай ук Грант исәбенә финанслашу күздә тотыла торган чыгымнар планы тапшырыла, биредә сатып алына торган мөлкәтнең, башкарыла торган эшләрнең, күрсәтелә торган хезмәтләрнең исемнәре, аларның саны, финанслау чыганаклары күрсәтелә, болар 7 нче кушымта нигезендә кәгазьдә килеш һәм электрон саклагычта бирелә.

3.1.4. Мөрәҗәгать итүче паспортының күчермәсе;

3.1.5. КФХның исәп-хисап счетыннан конкурска заявка кабул ителү көненә кадәр 30 календарь көннән дә алданрак булмаган вакытта бирелгән, сатып алына торган һәр мөлкәтнең, башкарыла торган эшләрнең хакыннан кимендә 10 процент күләмендә акчалары булуны раслый торган банк өземтәсе (граждан өчен шәхси счеттан);

3.1.6. Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан аерым затның аңардагы күчемсез мөлкәт объектларына (проектта катнаша торган объектларга) хокуклары турында вәкаләтле орган тарафыннан таныкланган һәм конкурс заявкасын бирү көненә кадәр 30 көннән дә алданрак булмаган вакытта бирелгән өземтә;

3.1.7. Җирле сметалар һәм схема-сызымнар белән (булачак эшләрнең урыннарыннан фотографияләр, объект булганда - аның тышкы һәм эчке яктан фотографияләрен) җыелма смета исәп-хисабы, үз-үзен тәэмин итү торган оешмага (алга таба - СРО) проектлауга рөхсәтнең күчермәсе (Грантны төзүгә яисә реконструкцияләүгә тотканда);

3.1.8. Төзүгә (реконструкцияләүгә) рөхсәт (Грантны төзүгә яисә реконструкцияләүгә тотканда) һәм (яки) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә урнашкан торак булмаган, законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән биналарга ямилекчелек хокукы турында таныклык яисә арендалау шартнамәсе;

3.1.9. Үз инициативасы белән салым органына Мөрәҗәгать итүченең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча үтәлмәгән йөкләмәләре юклыгы турында белешмә (КНД буенча 1120101 Код формасы буенча), иминләштерелгән затның – КФХ башлыгының мәҗбүри пенсия иминияте системасында шәхси счетының торышы турында белешмә (СЗИ-6 формасы буенча), салым түләүченең шәхси номеры таныклыгы күчермәсен тапшыра. Әгәр күрсәтелгән документлар КФХның үз инициативасы белән тапшырылмаса, Министрлык аларны ведомствоара үзара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала (КФХ өчен);

3.1.10. Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык, 8 нче Кушымта формасы буенча;

3.1.11. Мөрәҗәгать итүченең КФХ эшчәнлек алып бара торган яки алып бару планлаштырыла торган муниципаль берәмлеккә Грант алган көннән иң күбе 12 ай эчендә даими яшәү өчен күченеп килүе турында йөкләмә (башка муниципаль берәмлектә яшәгәндә);

3.1.12. Мөрәҗәгать итүченең хезмәт кенәгәсе күчермәсе (булганда);

3.1.13. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлегенә (проектта катнаша торган объектларга) милекчелек хокукын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлеген арендалау (кимендә 7 елга) шартнамәсе күчермәсе;

3.1.14. Мөрәҗәгать итүченең җире, җитештерү биналары, техникасы, җайланмалары, авыл хуҗалыгы хайваннары булу турында белешмә, 9 нчы Кушымта нигезендә;

3.1.16. КФХ хуҗасының милкендәге авыл хуҗалыгы техник чарасының булуын (булганда) раслый торган паспорт;

3.1.17. Документлар исемлеге, 10 Кушымта нигезендә.

Мөрәҗәгать итүче Грантның бер өлешен үзе әгъза булып торучы кооперативның бүленмәс фондын булдыруга тотуны планлаштырган очракта, Мөрәҗәгать итүче әлеге пунктның 3.1 пунктчасы нигезендә тапшырыла торган документларга түбәндәге өстәмә документларны тапшыра:

- КФХ тарафыннан авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының бүленмәс фондына кертелгән Грант акчаларын куллану күрсәтелгән авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының чыгымнар планы, 11 нче Кушымта нигезендә;

- гамәлгә кую документларының күчермәләре, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының конкурска заявка бирелгән датага гамәлдә булган редакциясендәге устав;

- авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы рәисе тарафыннан имзаланган һәм кооператив мөһере сугылган (булса) кооператив әгъзалары исемлеге;

- авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының гомуми җыелышыннан, КФХдан - кооператив әгъзасыннан алынган Грант акчалары өлешен исәпкә алып, бүленмәс фондны булдыру һәм аның акчаларын тоту тәртибе турында карар күчермәсе;

- кооперативның үз әгъзаларының табышлы җитештерүе һәм җитештерелә торган продукция күләмен арттыру күздә тотыла һәм «Агростартап» гранты акчаларыннан Мөрәҗәгать итүче тарафыннан финанслашуга тәкъдим ителә торган чыгымнар планы проекты кергән бизнес-планы ;

- Грант акчалары тотылып беткән датадан кимендә 5 ел буена кооператив тарафыннан эшчәнлек алып баруга һәм кооперативның Бизнес-планында каралган эшчәнлек күрсәткечләренә ирешүгә йөкләмә , ул авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары рәисе тарафыннан имзаланган һәм аңа мөһер сугылган булырга тиеш;

- авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының соңгы хисап чорына бухгалтерлык (финанс) хисабы күчермәсе (форма № 1 - спр);

- авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы рәисенең шәхси белешмәләрне тикшерүгә ризалыгы, 8 нче Кушымта формасы нигезендә;

- авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының ревизия берлегендә әгъза булып торуын раслый торган белешмә, ул ревизия берлеге рәисе тарафыннан имзаланган һәм аңа мөһер сугылган (булса) булырга тиеш.

3.2. Белешмәләрнең дөреслеге һәм тапшырылган документларның дөреслеге өчен Мөрәҗәгать итүче җаваплы була. Документларны әзерләүгә һәм аларны конкурс комиссиясенә тапшыруга бәйле чыгымнарны Мөрәҗәгать итүче тота.

Таныклау таләп ителә торган һәм берничә биттән торучы документлар тапшырганда, һәр бите таныклана. Документларның төп нөсхәләре проектны яклауганда конкурс комиссиясе тарафыннан чагыштыру өчен тапшырыла.

Әлеге Нигезләмәнең 3.1 бүлегендә күрсәтелгән документлар тегелгән, номерланган, вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган һәм кооператив мөһере белән беркетелгән (мөһере булса) булырга тиеш. Мөһер белән беркетелгән (мөһере булса) һәм вәкаләтле зат имзасы белән таныкланган (юридик затлар өчен) яисә үз кулы белән таныкланган (Мөрәҗәгать итүче өчен) төзәтүләрдән тыш, чистартулар һәм төзәтүләр рөхсәт ителми.

Әлеге Нигезләмәнең 3.1 бүлегендә күрсәтелгән документлар сайлап алу конкурсы уздыру турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән срокларда һәм адрес буенча тапшырыла.

Грант бирү тәртибе һәм документлар формалары турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында: http: //agro.tatarstan.ru/ – «Фермерларга, авыл хуҗалыгы кооперативларына грантлар һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларга субсидияләр» бүлегендә, алга таба – 2019-2024 елларга Татарстан Республикасында «Агростартап» бүлекчәсе (алга таба текст буенча - Министрлыкның рәсми сайты) урнаштырыла.

Мөрәҗәгать итүче үз ихтыяры белән конкурс комиссиясенә (кара-каршы әңгәмә вакытында) КФХны Программада потенциаль катнашучы буларак уңай тасвирлый торган һәм конкурс комиссиясе карарына тәэсир итәргә мөмкин булган түбәндәге документларны тапшыра:

а) җирле үзидарә органнарыннан КФХның үсешен, аның җитештерү күрсәткечләре динамикасын, шулай ук Грант бирүнең социаль-икътисадый нәтиҗәсен һәм максатка яраклы булуын тасвирлый торган күрсәтмә хатлар;

б) җитештерү биналарының, авыл хуҗалыгы хайваннарының, техника һәм җайланмаларның фотографияләрен (шул исәптән төзелеп бетмәгән төзелешнең);

в) 2.5, 3.1 пунктларда билгеләнгән таләпләр нигезендә заявка бирелгән вакыттан эшләнеп беткән документларны;

г) массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыккан язмаларны.

## 4. Заявкаларны кабул итү һәм карау

4.1. Грантлар бирү буенча сайлап алу конкурсында катнашуга заявкаларны кабул итү башлану турында белдерү «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында: http: //agro.tatarstan.ru/ – «Фермерларга, авыл хуҗалыгы кооперативларына грантлар һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларга субсидияләр» бүлегендә конкурс заявкалары кабул итү тәмамлануга кадәр утыз көн кала урнаштырыла.

Белдерүдә конкурс уздыруның урыны һәм вакыты, конкурс заявкалары кабул итү башлану һәм тәмамлану вакыты, элемтә телефоннары, Министрлык сайтының конкурс шартлары турында, заявкалар бирү һәм норматив хокукый документлар белән танышу тәртибе турында мәгълүмат урнаштырыла торган бүлеге күрсәтелә.

4.2. Заявкалар кабул итә башлау срогы белдерү басылып чыккан көннән соң килүче көн була. Белдерүдә күрсәтелгән срок узгач мөрәҗәгать итүчеләрдән заявкалар кабул ителми. Әгәр конкурс катнашуга бер заявка да тапшырылмаса, конкурс узмаган дип таныла.

Алынган заявкалар һәм документлар алар кергән саен заявкаларны теркәү кенәгәсендә теркәлә, ул номерланган, төпләнгән һәм конкурс комиссиясе секретаренең имзасы белән таныкланган һәм Министрлык мөһере белән беркетелгән булырга тиеш. Теркәгәндә заявкага керү номеры бирелә.

Әлеге Нигезләмәнең 3.1. бүлегендә күрсәтелгән документлар җаваплы затка кәгазьдә килеш тапшырыла, 3.1.3 (бизнес-план), 3.1.7 (локаль-смета исәп-хисабы, (КФХда булган җитештерү биналарының, техниканың, хайваннарның һәм кош-кортның фотодокументлары) һәм 3.1.2 (анкета) пунктчаларында күрсәтелгән документлар өстәмә рәвештә электрон рәвештә дә тапшырыла. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан конкурс комиссиясенә тапшырыла торган барлык документларның исемнәре, алардагы битләр саны ике нөсхәдә төзелә торган исемлеккә кертелә. Тапшырылган документлар җаваплы зат

тарафыннан исемлек белән чагыштырып тикшерелгәннән соң (9 нчы Кушымта), алар, конвертка салынып, ябыштырыла, конверт КФХ мөһере белән мөһере белән (булса) таныклана. Конвертта шулай ук программаның исеме, проект эшчәнлегенең юнәлеше һәм аның куәте, Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм адресы күрсәтелә. Исемлек конвертка салынмый. Документларны кабул иткәндә исемлектә документлар кабул итүне раслый торган тамга куела, кабул итү датасы һәм теркәү номеры куела. Исемлекнең кабул итү тамгасы белән белән бер нөсхәсе Мөрәҗәгать итүчедә кала, ә икенчесе документлар пакетына өстәлеп куела.

Заявканы һәм документларны кабул иткәндә аларның тулылыгы һәм билгеләнгән таләпләргә туры килүе тикшерелми.

## 5. Конкурс комиссиясенең функцияләре һәм бурычлары

5.1. Конкурс комиссиясе үз эшчәнлегендә законнарга, әлеге Нигезләмәгә таяна һәм үз эшен авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләренә дәүләт ярдәме инфраструктурасын тәшкил итүче оешмалар, иҗтимагый оешмалар, КФХлар һәм аграр профильдәге мәгариф оешмалары белән хезмәттәшлектә оештыра.

5.2. Конкурс комиссиясенең төп бурычлары түбәндәгеләр була:

грант алу өчен Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган конкурс документациясен вакытында, ачык һәм объектив карауны тәэмин итү;

проектларның тулылыгын һәм дөреслеген, икътисадый нәтиҗәлелеген, Татарстан Республикасы икътисады өчен социаль әһәмиятлелеген һәм аңа дәүләт ярдәме күрсәтүнең максатка ярашлы булуын билгеләү өчен аларга экспертиза уздыру;

конкурста җиңүчеләрне һәм аларга бирелә торган грантлар күләмнәрен билгеләү.

5.3. Конкурс комиссиясе Министрлык боерыгы белән кимендә 12 кешедән оештырыла һәм аның составына конкурс комиссиясенең рәисе, рәис урынбасары, конкурс комиссиясе әгъзалары һәм секретаре (тавыш бирү хокукына ия түгел) керә. Конкурс комиссиясе составына дәүләт Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәрләр, иҗтимагый оешмалар, авыл хуҗалыгы өлкәсендә берлекләр, берләшмәләр һәм белем бирү оешмалары вәкилләре керә. Конкурс комиссиясе составында дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәткәрләр саны – 50 проценттан кимрәк.

Конкурс нәтиҗәләре белән шәхсән кызыксынучы затлар, шул исәптән конкурста катнашуга гариза биргән йә бу заявкаларны биргән КФХда торучы затлар яки конкурста катнашучылар тәэсир итәргә мөмкин булган затлар комиссия әгъзалары була алмыйлар.

Конкурс комиссияс рәисе:

конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм аңа йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җаваплы була;

конкурс комиссиясе әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә;

конкурс комиссиясе утырышларын алып бара, конкурс комиссиясе утырышлары беркетмәләрен әзерләүне һәм конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларның үтәлүен тикшереп тора.

5.4. Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары, утырышта конкурс комиссиясе рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын үти.

5.5. Конкурс комиссиясе секретаре:

заявкалар кабул итү тәмамланганнан соң 5 эш көне эчендә конкурс комиссиясе утырышында каралырга тиешле документлар белән заявкалар исемлеген төзи;

заявкалар кабул итү тәмамланган вакыттан 5 эш көне эчендә документларны эксперткомиссиясе каравына тапшыра;

конкурс комиссиясе утырышы өчен материаллар әзерләүне оештыра, конкурс комиссиясе әгъзаларының утырышта катнашуын һәм конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсен алып баруны тәэмин итә;

заявкалар кабул итү тәмамланганнан соң 15 эш көне эчендә конкурс комиссиясе утырышын оештыра, аңа Мөрәҗәгать итүчеләрне кара-каршы әңгәмә өчен чакыра;

конкурс тәмамланганнан соң 30 эш көне эчендә барлык заявкаларны һәм документларны, шулай ук конкурс комиссиясе тарафыннан алынган барлык документларны Министрлык архивына тапшыра, алар анда Грант алынган датадан 7 ел буена саклана.

5.6. Йөкләнгән вәкаләтләрне башкару, консультацияләр бирү, тапшырылган документларны өйрәнү, аларга экспертиза уздыру һәм балларны санау өчен конкурс комиссиясе эксперт советын җәлеп итә. Эксперт советы Министрлык боерыгы белән Министрлык белгечләреннән төзелә, аның составы кимендә 12 кешедән - аның рәисеннән, секрет ареннан һәм эксперт советы әгъзаларыннан тора.

Эксперт советы:

Конвертларны ача һәм документларның барлыгын тикшерә; Мөрәҗәгать итүченең һәм ул тапшырган документларның әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерә:

эксперт советының эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм үзенә йөкләнгән вәкаләтләрне билгеләнгән срокка үтәү өчен җаваплы була; эксперт советы әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә; тәкъдим итү характерындагы бәяләмәне конкурс комиссиясе каравына кертә.

Эксперт советы рәисе урынбасары эксперт советы рәисе булмаган очракта аның вазыйфаларын башкара.

Эксперт советы секретаре эксперт советы утырышын оештыра һәм конкурс комиссиясе өчен эксперт советы бәяләмәсен әзерли.

Эксперт советы утырышы Мөрәҗәгать итүчеләрнең конкурска заявкаларын кабул итү тәмамланган көннән башлап 5 эш көненнән дә соңга калмыйча уздырыла.

Рәис яисә рәис урынбасары (рәис булмаганда) утырыш уздыру вакытын һәм урынын билгели, шулай ук эксперт советы утырышларының көн тәртибен раслый, эксперт советы утырышы беркетмәсен имзалый.

Утырышны чакыруны эксперт советы секретаре тәэмин итә. Эксперт советы утырышын уздыру датасы һәм урыны турында мәгълүмат, шулай ук утырышның көн тәртибе эксперт советы әгъзаларына утырыш көненә кадәр 2 көннән дә соңга калмыйча җиткерелә.

Эксперт советы утырышында эксперт советы әгъзаларының кимендә яртысы катнашкан очракта, ул вәкаләтле була. Эксперт советы әгъзалары утырышта карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышканда тигез хокуклы булалар.

Эксперт советы карарлары беркетмә итеп рәсмиләштерелә, алар эксперт советы рәисе, эксперт советы рәисе урынбасары, эксперт советы секретаре һәм эксперт советы әгъзалары тарафыннан имзалана. Беркетмәдә түбәндәгеләр күрсәтелә: утырыш узган дата һәм урын;

эксперт советы әгъзаларының составы (фамилияләре, инициаллары) һәм утырышта катнашкан башка затлар (фамилияләре, инициаллары); көн тәртибе; кабул ителгән тәкъдимнәр.

Эксперт советы конкурс комиссиясе каравына тәкъдим характерында бәяләмә чыгара.

5.7. Конкурс комиссиясе заявкалар кабул итү тәмамланган көннән 30 эш көне эчендә тапшырылган документларны карый, конкурста катнашучыларның исемлеген төзи, тапшырылган бизнес-планнарның Нигезләмәгә туры килүен бәяли, баллар санын саный һәм аларны бәяләү ведомостена кертә, конкурста сайлап алынган җиңүчеләрне билгели һәм конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсен (алга таба - беркетмә) рәсмиләштерә;

Кара-каршы әңгәмә барышында конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы заявкалардагы мәгълүмат һәм Мөрәҗәгать итүченең бирелгән сорауларга җаваплары нигезендә тиешле карарны кабул итә һәм һәр Мөрәҗәгать итүчегә карата тавыш бирү кәгазенә язып куя, шунда ук бирелә торган грант күләмен күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче әлеге Нигезләмәнең 3.1. пунктында күрсәтелгән документлар пакетын тулысынча тапшырмаган очракта, конкурс комиссиясе кара-каршы әңгәмә барышында Мөрәҗәгать итүченең заявкасын кире кага.

5.8. Конкурс комиссиясенең карары, конкурс комиссиясе составының яртысыннан артыгы булганда, гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, конкурс комиссиясе утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

Бертигез баллар алган берничә дәгъвачы булганда, катнашучыларның санлы составы буенча грантлар саны фактта җитәрлек булмаса, Грант «Конкурска заявкалар теркәү журналы»нда заявкасы алданрак вакытта теркәлгән дәгъвачыга бирелә.

Тавыш бирү кәгазьләрендә конкурс комиссиясе әгъзалары белдергән карарлар нигезендә секретарь конкурс бюллетенен төзи. Тавыш бирү кәгазьләре һәм конкурс бюллетене беркетмәгә өстәп куела.

Конкурс комиссиясе утырышлары кирәк саен уздырыла. Конкурс комиссиясе әгъзалары утырышка рәис хәл итүе буенча чакырыла. Утырышка кадәр өч көн алдан конкурс комиссиясе секретаре Мөрәҗәгать итүчеләрнең электрон рәвештә тапшырылган, карауга әзерләнгән документларын һәм эксперт советының бәяләмәсен конкурс комиссиясе әгъзаларына өйрәнү өчен җибәрә.

Конкурс нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында конкурс комиссиясе тарафыннан карар кабул ителгән көннән 10 эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

5.9. Конкурс комиссиясе эксперт советы бәяләмәсе һәм Мөрәҗәгать итүчеләр тапшырган документларны анализлау нигезендә, түбәндәге критерийларга таянып, конкурста җиңүчеләрне билгели:

| № т/с | Критерийлар исеме | Күрсәткечләр | Балларда бәяләү |
|---|---|---|---|
| 1 | Ферманың юнәлеше | сөтчелек | 3 |
| | | эре мөгезле терлекләр симертү | |
| | | ат үрчетү | 2 |
| | | бәрәңге үстерү | |
| | | яшелчәчелек (ачык һәм ябык грунтта) | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | балыкчылык | 1 |
| | | сарык, кәҗә үрчетү | |
| | | бөртекле, кузаклы, азык һәм техник культурлар җитештерү | |
| | | җиләк-җимеш культуралары үстерү | |
| | | куян үрчетү | |
| | | гөмбәчлек | |
| | | авыл хуҗалыгы хуҗалыгы кошчылыгы | |
| | | умартачылк | |
| 2 | Мөрәҗәгать итүченең крестьян (фермер) хуҗалыгы урнашкан урындагы яшәү шартлары | милекчелектәге торак | 2 |
| | | милекчелектә булмаган торак (бергә яшәү яисә уртак файдалану) | 1 |
| 3 | Авыл хуҗалыгы эшчәнлеге алып бару өчен авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлеге булу | милекчелектә, бушлай файдалануда | 3 |
| | | озак сроклы файдалануда, 7 елдан да ким булмаган сроклы | 2 |
| 4 | Авыл хуҗалыгы эшчәнлеге өчен җитештерү һәм склад биналары булу (шәхси ярдәмче хуҗалыкка карамаган) | милекчелектә | 3 |
| | | арендада | 2 |
| 5 | Мөрәҗәгать итүченең милкендә заявка бирелгән вакытка үзйөрешле авыл хуҗалыгы техникасы булу (берәмлекләрдә) | 3 һәм аннан күбрәк | 2 |
| | | 1дән 2гә кадәр | 1 |
| 6 | бизнес-планның үзен аклау срогы | 1 елдан 3 елга кадәр | 3 |
| | | 3 ел 1 айдан 5 елга кадәр | 2 |
| | | 5 ел 1 ай һәм аннан күбрәк ел | 1 |
| 7 | КФХның авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларында әгъза булып торуы | кооператив әгъзасы | 2 |
| | | кооперативта әгъзалары түгел | 0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| 8 | Мөрәҗәгать итүченең проектны уңышлы башкару буенча төп факторларны белүен бәяләү (кара-каршы әңгәмәдән соң куела) | | 0дән 10 баллга кадәр |

5.10. Бәяләнә торган һәр проект буенча 5.9 пунктта күрсәтелгән критерийлар буенча баллар суммасы буларак билгеләнә торган йомгаклау баллары чыгарыла. Баллар бары тик тегелгән документлар буенча гына исәпләнә, конкурс комиссиясе утырышына гына тапшырылган документлар балл суммасына кертелми. Иң күп җыелган баллар саны 28гә тиң. Конкурс комиссиясе тарафыннан уңай карар чыгару өчен 12 балл җыярга кирәк.

5.11. Беркетмә конкурс комиссиясе рәисе яисә аның урынбасары, секретаре һәм конкурс комиссиясенең утырышта катнашкан әгъзалары тарафыннан имзалана. Беркетмә имзаланганнан соң Министрлык биш эш көне эчендә конкурс нәтиҗәләрен раслау турында боерык чыгара һәм аны Министрлыкның Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә җибәрә. Министрлык конкурста җиңүчеләрне раслау турында Министрлык боерыгы чыккан көннән 3 эш көне эчендә электрон элемтә аша конкурста җиңүчеләргә хәбәр итә, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында конкурста җиңүчеләр исемлеген урнаштыра.

5.12. Министрлыкның рәсми сайтында җиңүчеләр исемлеге урнаштырылган көннән исәпләнә торган ун эш көне эчендә Грант алучы Министрлык белән 10 нчы Кушымта формасы нигезендә Грант бирү турында шартнамә (алга таба - Шартнамә) төзи.

5.13. Әгәр конкурска бирелгән заявкалар буенча игълан ителгән Грантлар суммасы яисә конкурста откан заявкалар буенча Грантлар суммасы бүлеп бирелгән акчалардан кимрәк булса, Министрлык әлеге Нигезләмә нигезендә өстәмә конкурс игълан итә.

## 6. Грантны бирү һәм кайтару тәртибе

6.1. Министрлык Татарстан Республикасы бюджет акчаларын төп бүлүче була һәм акчаларны Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы идарәсендә ачылган үзенең шәхси счетыннан биш эш көне эчендә Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының муниципаль районнардагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе идарәләренең (алга таба – Идарә) Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы идарәсендә ачылган шәхси счетларына күчерә.

Идарәгә акчалар күчерү өчен түбәндәгеләр нигез була: 12 нче Кушымдагы форма буенча Шартнамә, 13 нче Кушымтадагы форма буенча алучылар кысаларында Татарстан Республикасы муниципаль районына тиешле грантлар турында җыелма белешмә-исәп-хисап, 14 нче Кушымта нигезендә КФХның

чыгымнар планы, Грант акчаларының бер өлешен кулланып, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының чыгымнар планы (Грант акчалары өлешен авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының бүленмәс фондына керткәндә).

6.2. Министрлык җыелма белешмә-исәп-хисапны, Шартнамәне һәм чыгымнар планын кергән саен кенәгәдә теркәп бара, ул номерлана, тегелә һәм Министрлык мөһере белән беркетелә. Теркәү язуында теркәлү номеры, документларны кабул итү датасы һәм конкурс комиссиясе нәтиҗәләре буенча Грант суммасы языла.

6.3. Документлар теркәлгән көннән соң 5 эш көне эчендә Министрлык кергән документларны тикшерә һәм КФХның чыгымнар планын һәм(яисә) «Агростартап» Гранты акчаларының өлеше кергән авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының чыгымнар планын, Грант алучы тарафыннан әлеге 6.2. пункты нигезендә тапшырылган белешмә-исәп-хисапны һәм Шартнамәне имзалый.

6.4. Мөрәҗәгать итүчегә грант бирүдән баш тарталар, әгәр:

әлеге Нигезләмәнең 3.1. пунктында каралган документлар пакеты тулы тапшырылмаган булса;

әлеге Нигезләмәнең 6.1. пунктлары нигезендә тапшырылган документларда белешмәләрнең, исәп-хисапларның факттагы белешмәләргә, исәп-хисапларга туры килмәве ачыкланса.

6.5. Министрлык грантны Идарәләрнең Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы идарәсендә ачылган шәхси счетларына күчерү өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментына түбәндәгеләрне тапшыра:

а) сайлап алу конкурсында җиңүчеләрне раслау турында Министрлык боерыгын;

б) 6.1. пунктта күрсәтелгән, әлеге белешмә-исәп-хисапны һәм Шартнамә күчермәсен.

6.6. Идарә Грантларны үзенең шәхси счетына кергән көннән 5 эш көне эчендә КФХларның Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы идарәсендә ачылган шәхси счетларына күчерә.

6.7. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары Грантлар бирү максатларының, шартларының һәм тәртибенең КФХлар тарафыннан үтәлүен законнар нигезендә тикшереп торалар.

6.8. Грант алучылар «Грант бирү күләме һәм шартлары» дигән 2 бүлектә күрсәтелгән Грант бирү шартларын бозган очракта, законнар һәм Шартнамә нигезендә җаваплы булалар.

6.9. Грант федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслау лимитларын исәпкә алып бирелә. Грант алуга сайлап алу конкурсын узган заявкаларны канәгатьләндерү өчен аларны финанслау иң күп җыелган баллар саны буенча әлеге Нигезләмә нигезендә чиратлылык тәртибендә башкарыла.

6.10. Грант бирүнең әлеге Нигезләмәдә һәм Шартнамәдә билгеләнгән тәртибе һәм шартлары бозылу фактлары ачыкланган, конкурска дөрес

булмаган белешмәләр һәм документлар бирелгән, хисап тапшырылмаган, грант акчалары максатчан кулланылмаган, шулай ук грантлар белән нәтиҗәле күрсәткечләргә ирешелмәгән һәм максатчан күрсәткечләр бозылган очракта, бирелгән Грантлар Министрлыктан тиешле таләп алынганнан соң алтмыш календарь көн эчендә бюджет законнары нигезендә федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты керемнә кире кайтарыла.

6.11. Грант бирү турында шартнамәдә каралган очракларда, Грантның 18 ай эчендә кулланылмый калган өлеше әлеге срок узгач утыз календарь көн эчендә федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты керемнә кире кайтарылырга тиеш.

6.12. Әлеге Нигезләмәнең 6.10 һәм 6.11 пунктларында күрсәтелгән акчаларны федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты керемнә ихтыярый рәвештә кайтарудан баш тарткан очракта, алар законнар нигезендә мәҗбүри тәртиптә алынырга тиеш.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2019 елның 17 июлендә 148/2-пр номерлы боерыгы белән расланган Нигезләмәгә 1 нче кушымта

"КИЛЕШТЕРЕЛДЕ":
Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы _______________ муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы

________________________________

________________________________

Ф.И.АТ.ис. имза

**Татарстан Республикасы ___________ муниципаль районы ____________авыл җирлегенең КФХ башлыгы**

**_______________________________________**

(Ф.И.Ат.ис.)

____________________

(датага)

**Грант акчаларын тотуын исәпкә алуның**
**ҖЫЕЛМА РЕЕСТРЫ**

Грант суммасы, мең сум Юнәлеше

____________________

| № т/с | Түләүне раслый торган доку-ментның исеме | Доку мент ның дата-сы | Доку-Мент-ның номе-ры | Кайдан (сату-чының исеме) | Сатып алынган товар-матди кыйммәтләр-нең исеме (терлекләр,тө-зелеш материаллары, техника, хез-мәт күрсәтүләр һ.б.) | Үлчәү берәмлеге (данә, баш, куб.метр, килограмм) | Сан | Бәясе (бер. берәм-лек өчен, сумнар-да) | Сум-масы, сумнарда | Финанслау чыганагы (грант, җәлеп ителгән акчалар яисә үз акчалары) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| 1. | | | | | | | | | | |
| 2. | | | | | | | | | | |
| | Барысы: | X | X | X | X | X | | X | | |

Белешмәләрнең дөреслеген раслыйм: КФХ башлыгы

имза, мөһер (булса) _______________________ _____________

(Ф.И. Ат. ис.)

дата

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм

азык-төлек министрлыгының

2019 елның 17 июлендә 148/2-пр номерлы

боерыгы белән расланган

Нигезләмәгә 2 нче кушымта

"КИЛЕШТЕРЕЛДЕ":
Татарстан Республикасы
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының
_______________ муниципаль районындагы
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы
___________________________
___________________________
(имза) (Ф.И. Ат.ис)

**"2019-2024 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыкларын булдыру һәм үстерү" ведомсто программасы нигезендә «Агростартап» проекты буенча ТР__________________муниципаль районыннан Грант алучы КФХ эшчәнлеге турында**

**БЕЛЕШМӘЛӘР**

(муниципаль район исеме, Грант алучының фамилиясе, исеме, атасының исеме)

1. Терлекчелек буенча җитештерү күрсәткечләре: ______________________________________________

| № т/с | Хайваннар | | Җитеште-релгән авыл хуҗалыгы продук-циясе күләме | Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләме | | Авыл хуҗалыгы продукция-сен сату күләме | | Табыш, мең сум | Барлык чыгым-нар, мең сум | Табыш-лылык, процент | Сату бәясе, сум/ кило-грамм |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Авыл хуҗалы-гы хайван-нарының исеме | Саны, баш | | тонна | сум | тонна | сум | | | | Г |
| 1 | | | Сөт | | | | | | | | |
| 2 | | | Ит | | | | | | | | |
| 3 | | | һәм башкалар | | | | | | | | |
| 4 | | | | | | | | | | | |
| Барысы: | | | | | | | | | | | |

1. Үсемлекчелек буенча җитештерү күрсәткечләре:

| № т/с | Җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясенең исеме | Урып-җыю мәйданы, гектар | Уңдырыш-лылык тонна/ гектар | Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештетү күләме | | Авыл хуҗалыгы продукциясен сату күләме | | Табыш, мең сум | Барлык чыгымнар, мең сум | Табыш-лылык, процент | Сату бәясе, сум/ килограмм |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | тонна | сум | тонна | сум | | | | |
| 1 | бөртекле һәм кузаклы культуралар | | | | | | | | | | |
| 2 | азык культуралары (күпьеллык үләннәр - печән) | | | | | | | | | | |
| 3 | бәрәңге | | | | | | | | | | |
| 4 | яшелчәләр | | | | | | | | | | |
| 5 | һәм башкалар | | | | | | | | | | |
| 6 | | | | | | | | | | | |
| Барысы: | | | | | | | | | | | |

2. Салым салу, хезмәткәрләрнең  саны һәм аларның  хезмәт хакы:

| № т/с | Хуҗалык хезмәткәрләренең белгечлеге исеме | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Исәпләнгән хезмәт хакы, мең сум | Салымнар | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Барлык салымнар, сум | шул исәптән | | | | |
| | | | | | Хезмәт хакыннан күчерелә торган акчалар, сум | Җир салымы, сум | Мөлкәткә салым, сум | Транспорт салымы, сум | Бердәм авыл хуҗалыгы салымы, сум |
| 1 | КФХ башлыгы | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | | |
| 3 | | | | | | | | | |
| 4 | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | |

3. Җир кишәрлеге  мәйданы (га)

арендада:

милектә:

Белешмәләрнең дөреслеген раслыйм:

КФХ башлыгы ______________________________________________
(Ф.И.Ат.ис.)
КФХ башлыгының элемтә өчен телефоны:

20__ел

(имза, мөһер (булса))

« »

(дата)

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2019 елның 17 июлендә 148/2-пр номерлы боерыгы белән расланган Нигезләмәгә 3 нче кушымта

Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары – конкурс комиссиясе рәисе
Р.Р. Хәбиповка

______________________________
(мөрәҗәгать итүченең Ф.И.Ат.ис., яшәү урыны адресы)

**20___елда «Агростартап» грантын алу конкурсында катнашуга Татарстан Республикасы _____________ муниципаль районыннан КФХ өчен**

**ЗАЯВКА**

Мин, ______________________________________ , _____________
(Мөрәҗәгать итүченең тулы рәсми исеме)

«2019-2024 елларга Татарстан Республикасында «Агростартап» проекты буенча крестьян (фермер) хуҗалыкларын булдыру һәм үстерү» ведомство программасында (алга таба - Программа) катнашучыларны конкурс буенча сайлап алуда катнашучылар составына мине кертүегезне сорыйм.

Программада катнашу шартлары белән таныштым һәм ризалыгымны белдерәм.

Шуның белән түбәндәгеләрне раслыйм:

1. КФХ башлыгы буларак эш урыны минем бердәнбер эш урыным булачак һәм, шушы КФХдан тыш, башка коммерциячел оешманы гамәлгә куючы (анда катнашучы) булмаячакмын;
2. КФХ _________________________________ - юридик зат (шәхси эшкуар) үзгәртеп кору, бетерү, банкротлык стадиясендә тормый;
3. КФХ Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив актлары нигезендә федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы

бюджетыннан Конкурс уздыру турындагы нигезләмәдә күрсәтелгән максатлар өчен акчалар алмады;

4. КФХның шулай ук башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләр, бюджет инвестицияләре буенча федераль бюджетка, Татарстан Республикасы бюджетына кайтарырга тиешле вакыты узган бурычы һәм федераль бюджетка, Татарстан Республикасы бюджетына түләнү вакыты узган башка төрле бурычы юк;

5. КФХның законнар нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча үтәлмәгән йөкләмәләре юк.

6. КФХ чит ил юридик заты түгел, шулай ук устав (җыелма) капиталында ташламалы салым салу режимын бирә торган һәм (яисә) финанс операцияләре уздырганда мәгълүматны (офшор зоналарны) фаш итүне һәм бирүне күздә тотмаучы дәүләтләрнең һәм территорияләрнең Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлегенә кертелгән дәүләт (территория) теркәлү урыны булган чит ил юридик затларының катнашу өлеше 50 процентлан артып китә торган Россия юридик заты түгел.

Заявкага өстәп тапшырылган документлардагы яисә аларның күчермәләрендәге барлык мәгълүмат дөрес, мин Грант бирүгә документларны карауда катнашучыларның аларны тикшерүләренә каршы түгел.

(мөрәҗәгать итүченең имзасы, мөһере (булса)

(заявка бирелгән дата)

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2019 елның 17 июлендә 148/2-пр номерлы боерыгы белән расланган Нигезләмәгә 4 нче кушымта

Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары – конкурс комиссиясе рәисе
Р.Р. Хәбиповка

______________________________
(мөрәҗәгать итүченең Ф.И.Ат.ис., яшәү урыны адресы)

**20___елда «Агростартап» грантын алу конкурсында катнашуга Татарстан Республикасы _____________ муниципаль районыннан гражданнар өчен**

**ЗАЯВКА**

Мин, ____________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең Ф.И.Ат. ис. тулысынча)

«2019-2024 елларга Татарстан Республикасында «Агростартап» проекты буенча крестьян (фермер) хуҗалыкларын булдыру һәм үстерү» ведомство программасында (алга таба - Программа) катнашучыларны конкурс буенча сайлап алуда катнашучылар составына мине кертүегезне сорыйм.

Программада катнашу шартлары белән таныштым һәм ризалыгымны белдерәм.

Шуның белән түбәндәгеләрне раслыйм:

1. КФХ башлыгы буларак эш урыны минем бердәнбер эш урыным булачак һәм, шушы КФХдан тыш, башка коммерциячел оешманы гамәлгә куючы (анда катнашучы) булмаячакмын;

